КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 16 июль г.Казань № 580

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән агросәнәгать комплексын кадрлар белән тәэмин итүгә дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2017 ел, 21 ноябрь, 893 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының иң яхшы крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы» республика конкурсын үткәрү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән агросәнәгать комплексын кадрлар белән тәэмин итүгә дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2017 ел, 21 ноябрь, 893 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 26 март, 173 нче; 2019 ел, 6 сентябрь, 789 нчы; 2020 ел, 10 март, 181 нче; 2020 ел, 14 май, 389 нчы; 2020 ел, 30 декабрь, 1247 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасының иң яхшы крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы» республика конкурсын үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

4.4.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4.5. Федераль салым хезмәтенең «Иминият кертемнәре буенча исәп-хисап формасын, аны тутыру тәртибен, шулай ук иминият кертемнәре буенча исәп-хисапны электрон формада тапшыру форматын раслау һәм Федераль салым хезмәтенең 2016 елның 10 октябрендәге ММВ-7-11/551@ боерыгы үз көчен югалткан дип тану турында» 2019 елның 18 сентябрендәге ММВ-7-11/470@ боерыгы нигезендә КНД 1151111 дигән форма буенча крестьян-фермер хуҗалыгы хезмәткәрләре саны турында мәгълүмат;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин